Көлү – сихәт, көлеп яшәү мәслихәт!

ISSN 0136-7110

Чаян



10

САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ ОКТЯБРЬ * 2024 * КАЗАН



Виктор БОГОРАД

Алмаз ХӘМЗИН

ЧЫДАМЛЫК

Бөтенесен күреп, белеп яшим,
Хаксызлыкның хәзер чиге юк.
Күрәләтә торып шуңа түзү –
Кешегә генә хас – эт тә юк!

Чагыштырам тормыш агышында
Ниләр генә безгә язмаган...
Афәт арты, афәт чыгып торган
Туп тавышы берчак тынмаган.

Киткән яуга илен сакларга дип,
Ир-затлары патша чакыргач.
Миллионлаган баш ятып калган –
Күпме ятим, алар кайтмагач...

Үксү тула һәр гаиләгә кереп,
Кара кайгы шәле иңнәрдә.
Ник шулай илне читләп узмый ул,
Гел керә бит безнең өйләргә?

Әле генә тыныч яши идек лә,
Матур иде тормыш итүләр.
Нигә һаман әйләнеп кайта соң бу –
Җәмгыятьне кабат сүтүләр?

Дошман түгел, үз янәшәңдә генә
Икән, нәфес тыя алмаган.
Коммунист иде элек, инде хәзер
Партиясендә ул – атаман!

Гаделлек өчен дигән булып болар,
Кул күтәреп, закон ясыйлар.
Инде андый көчәнүләреннән соң
Мохтаҗлылар чүплек казыйлар.

Заводлар да юкка чыккан бит,
Таланганда әле сизмәдек.
Кирәк хәзер, бик тә кирәк алар –
Их, Сәвитнең кадрен белмәдек.

Әвәл без барыбыз да "Иптәш" идек.
Тигез идек – байлар булмады.
Иптәшлектән күчтек "әфәнде"гә,
Әфәнделек тә юк, югалды.

Байлар калыкты бездә, бик зур байлар!
Байлар гынамы – олигархлар!
Бар байлыклары күчте чит илләргә,
Тулып аккан кебек арыклар.

Ялган чире басты бөтен җирне,
Парламентлар күчте шул эшкә.
Ришвәт дигән вирус керде илгә,
Вакцинасы юк бит тиешкә.

Минем гомер үтеп бара инде,
Аны төгәллисе генә бар.
Бер карасаң, мин бәхетле икән –
Вәхшилеккә каршы чыдам бар!

Анастасия ВАСИЛЬЕВА





ШОМБАЙ *болай диде...*

Хөрмәтле Чаян! Башлыгыбыз безгә колларына караган кебек карый.

Безне эштән соң да, ял көннәрендә дә эшләргә мәҗбүр итә. Хезмәт турында законнар турында ишетергә дә теләми! Авызыңны ачу була, кычкыра башлый: "Статья буенча куып чыгарам!" Тынарга туры килә: кемнеңдер ипотекасын, кемнеңдер эшен йә стажын югалтасы килми...

М. ГӘРӘЕВА

Чаллы.

– Таныш хәл! – диде Шомбай ага, укучыбызның хатын укып чыккач. **– Алтмыш яшемдә пенсиягә чыкканда хезмәт стажым алтмыш биш ел иде. Шул эштән соң калып эшләгәнгә күрә булгандыр инде...**

Александр БРЮХАНОВ

НӘРСӘДЕР КУШАЛАР...

– Мин ишеттем, – дип башлады сүзен ябык кына бер ханым, күзләрен йоммыйча. Бу аның әйтүенә чынлык өсти иде. – Сигареталарга тартасы килүне көчәйтер өчен нәрсәдер кушалар икән.

Ул юталлап куйды. Үзенең тәмәке тарту стажы күп булганын белдерү исәбеннәндер инде.

– Әйе, минем дә ишеткәнем бар, азык-төлеккә дә нәрсәдер кушалар икән өстәп. Ашаган саен ашыйсы килер өчендер... – дип хуплап куйды аны галәмәт юан хатын. Әйләнеп узардай түгел үзен...

– Минем дә ирем әйтте, аракыга да нәрсәдер кушып саталар, дип. Ул инде айнымыйча әллә ничә еллар буе туктый алмый әчә, – диде сеткасындагы шешәләрне шалтыратып, болай карап торырга тыйнак кына ханым...


– Суга да нидер кушалар, кранны ябарга онытсыннар дип. Күбрәк түләсеннәр өчен, – диде бер кечерәк буйлы хатын, кисәк маңгаена учы белән чәпелдәтеп, – бөтенләй онытканмын су алырга, – дип, тизрәк йөгерде...

– Телевизордан егерме бишенче кадр күрсәтәләр, күп итеп кирәкмәгән әйберләр алырга теләсеннәр өчен... – диде, беренче сүз башлаган ханым, кассада акчасын түләгән арада...

– Алга таба ничек яшәрбез, белмим, – дип кушылды аңа икенчесе, кулындагы авыр пакетны уң кулыннан сулына күчереп...

– Ә сез тырышып карагыз, – диде өченчесе, сеткасындагы сигез шешәсенә ишарәләп.

Алар һәрберсе үз ягына таба таралды, һавага да нәрсәдер кушып сибелгәнен уйламыйча һәм бу турыда беркемгә берни әйтмичә...


Вячеслав ШИЛОВ

Сергей КОКАРЕВ



Телефонны шалтырадылар...

Беркайчан да таныш булмаган кешеләр белән сөйләшмәгез, дигән иске әйтем бар. Ул күптәнннән, смартфоннар һәм пин-кодларга кадәр барлыкка килгән булса да, үзенең әһәмиятлелеген югалтмаган.

Сер түгел, күпләр көчәнмичә генә эшләп, шәп хезмәт хакы алып яту турында хыяллана. Шуңа күрә алар чамасыз беркатлы гражданнарның кесәләрен бушатырга омтылган мошенникларның тәкъдимнәреннән баш тартмыйлар. Мәсәлән, Алабугада яшәүче бер ханымга офис һәм кафеларның скриншотларын ясап, аларны сайтта урнаштырып акча эшләргә тәкъдим килгәч, ул шундук риза булган. Берьюлы аңа үз акчасына кунакханәләрдә урын бронировать итәргә дә кушканнар – ул акчалар, имеш, түләү белән бергә кайтарылачак. Берничә көн эчендә хатын отельләргә 400 мең сум күчергән. Ә менә вәгъдә ителгән акча белән тоткарлык килеп чыккан. Күңеленә шик төшеп, ханым күчеререлгән суммаларны кайтаруларын таләп иткән. Җавап итеп аңа... тагын 400 мең күчерергә тәкъдим иткәннәр. Ә аннан соң бөтенләй элемтәгә чыкмый башлаганнар. Эш бирүчеләрнең беркатлы Алабуга хатыны бронь салган номерларда кәеф-сафа корып яткан чаклары булгандыр, күрәсең...

Әлмәттә яшәүче егет тә иске әйтемдәге кисәтүне кабул итмәгән. Аңа телефоннан мошенник шалтыратып, үзен ЖКХ хезмәткәре итеп таныткан һәм тиздән электр счётчикларын алыштыру булачагы турында хәбәр иткән. Ә аның ризалыгын алу өчен "хезмәткәр" СМС буенча алынган кодны хәбәр итүен сораган. Нефть башкаласында яшәүче беркатлы егет шулай иткән дә. Берникадәр выкыт узып, счётчиклар алыштыру планлаштырылмаганы ачыклангач, "коммуналь хезмәткәрләргә" шалтыраткан. Күр тавышлы хатын-кыз намуссыз кешеләрнең аның "Госуслуги" битенә керүләре турында хәбәр иткән. Ул гына да түгел, аның исеменнән дисталәгән төрле банкларга мөрәҗәгать итеп, зур суммага кредит ача башлаганнар, имеш. Куркудан башын югалткан бичара шул ук "финанс ярдәмчеләре" киңәше буенча, булмаган бурычны түләр өчен үзе 400 мең сумга кредит алган. Аннары, автомобилен залогка салып, бу бурычны тагын 600 меңгә арттырган.

Егет мошенникларга акча күчергән арада, аңа тагын шалтыратканнар һәм билгесез кешеләрнең аның исеменә шәхси предприятие ачуы турында әйткәннәр, ә аны ябар өчен тиз генә тагын 500 мең кертергә кирәклеген хәбәр иткәннәр. Акылын җуя язган егет дуслары һәм туганнарыннан бурычка алган. Һәм бары тик соңгы "транш"тан соң гына таныш булмаган кешеләр белән сөйләшуләрнең нәрсәгә китерүен аңлап алган. Аларны хәзер полиция эзләп табарга омтыла...


Шундый ук ысул белән Яшел Үзәндә яшәүче бер хатынны түп башына утырткannар. Аңа хезмәт күрсәтү килешүен озайту тәкъдиме белән кәрәзле элемтә компаниясе операторы шалтыраткан. Аны-моны көтмәгән абонентка аңа СМС буенча килгән кодларны хәбәр әйтеп биргән. Тиздән аны "Госуслуги" "хезмәткәрләреннән" һәм Үзәк Банктан ул алган кредитлар турында хәбәрләр ташкыны басып киткән. Куркуга калган ханым аларны гамәлдән чыгарырга тотынган. Ике миллионын югалткач кына ул полициягә ярдәм сорап килгән.

Шуңа күрә, хөрмәтле иптәшләр, иске әйтемнәрне хәтерегездән чыгармагыз. Һәм беркайчан да таныш булмаган кешеләр белән сөйләшмәгез. Бигрәк тә телефон буенча...


Артём СУББОТКИН



Сергей КОКАРЕВ



Вячеслав ШИЛОВ



Константин ЧАХИРОВ



Михаил ЛАРИЧЕВ



• • •

Хәзерге мәктәпне тәмамлаган кайбер укучыларга, ЕГЭ имтиханнарын уңышлы тапшырганнан соң, "Урта белем аттестаты"н тантаналы рәвештә бирергә кирәк.

• • •

Әнисе баласын күз яшьләре белән мәктәпкә әзерли. Улы түзми, болай ди:

– Әни, үксемә инде, болай да күңелем болгана...

• • •

– Имтиханыңны ничек бирдең?

– Шәп итеп! Хәтта күзгә чакырып, биска кабатларга куштылар.

• • •

География укытучылары бернәрсә аңламый, бу уку елында ничек укытырлар. Ә яңа тарих укытучылары, гомумән, аптырашта.

• • •

Менә инде 30 ел беренче сентябрьдә минем кәефем бик әйбәт. Чөнки иртән уянам һәм беләм: мәктәпкә барасы юк.

• • •

"Танылган блогер" титулы – ул чама белән "танылган йомран" дигән мәгънәдә. Танылуын танылган ул, ләкин башка йомраннарга гына.

• • •

– Безнең тәрәзә астында спорт киемнәре кигән кешеләр кара пакетларга нәрсәдер тутыралар.

– Тыныч кына утыр, сузылып карама. Йә үтерүләре бар, йә субботникка чакырырлар.

• • •

– Кадерлем, син кайда?

– Пробкада барам.

– Пробка озынмы?

– Белмим. Мин беренче булып барам...

• • •

Хәзер чикләрне үтеп сәяхәткә чыгу кыенлашты. Югыйсә акыл мәгънәсендәге чикләрне без бернинди авырлыксыз үтәбез.

• • •

– Кайчан да булса "деликатность" дигән сүзне ишеткәнең бармы?

– Әйе, ишеттем... Кер юу машинамда андый режим бар!

• • •

– Ял итәргә Парижга барасыңмы?

– Юк. Нәрсә, анда барырга мин әллә Дуровмы!





ШАЙТАН АДВОКАТЛАРЫ

Владимир каласында ике адвокат законның икенче ягына барып чыкканнар. Уртак танышларына наркотиклар тараткан өчен полиция аны җаваплылыкка тартачак, дип хәбәр иткәннәр. Ышанычлырак булсын өчен, "яклаучылар" кузгатылган "җинаять эшеннән" аңа берничә ялган документ та күрсәткәннәр, ә эшне җайлар өчен өч миллион сум таләп иткәннәр. Акча тапшырган чакта аларны эләктергәннәр. Соңыннан адвокатларның бернинди дә элемтәләре булмавы, ә өч миллионны үзара бүлешергә җыенганнары ачыкланган.

МӘКЕРЛЕ ҮЧ

Приморьеда яшәүче берәү үзүзен төп башына утырткан. Ул ике Урта Азия кешесен бинада ремонт ясау өчен яллаган. Аванс биргән һәм Владивостоктан кире юл бәясен түләгән. Әмма гастарбайтерлар сөйләшенгән эшләрне башламаган да килеш аэропортка элдерткәннәр. Ачуы чыккан эш бирүче полициягә ике Азия кешесенең аэропортта бомба куеп, илдән китәргә җыенулары турында хәбәр салган. Мәкерле үч өчен диңгез буе егете шартлы рәвештә өч ел алган.

ҖИР АСТЫННАН ТАПКАННАР

Приморье краеның Кочевский районыннан үзен ана дип атаучы хатын үзенең кызына 150 мең сум алимент тиеш калган. Ләкин ул аларны йөрәк парәсенә түләргә җыенмаган да. Өенә приставлар килгәч, алар йозакка бикләнгән ишек кенә тапканнар. Җир биләмәләрен тикшерә башлагач, алар җирдән тырпаеп торган баш күреп алганнар. Алиментчы ана җир асты юлы казый икән. Хезмәткәрләр аны өскә тартып чыгарганнар һәм бурыч өчен аңа төрмә срогы янавы турында документлар тапшырганнар.


АШЫГЫЧ КОМПЬЮТЕР ЯРДӘМЕ


Мәскәүдә 76 яшьлек бер пенсионер төн уртасында ашыгыч ярдәм чакырткан. Медиклар бригадасы адрес буенча килеп җиткәч, анда көр, ләкин кәефе кырылган әбекәйне тапканнар. Аның смартфонында YouTube эшләмәве ачыкланган, ә әби аудиокитаплар укып йоклап китәргә иләнгән икән. Табиблар, видеохостингны көйләп, пациентны "терелткәннәр" һәм моның өчен бер тиен дә алмаганнар.

ПАТША һәм ШАМАКАЙ

Владимир СОЛДАТОВ рәсемнәре.







Рестәм ЗАРИПОВ

ТАП БУЛУ

Бармак битләре эзләре,
Төрлесе-төрле, үзгә
Язмышлар да кабатланмый,
Шул тәртип язган безгә...

Кеше тормышына кереш –
Кәмәнгә узган очрак,
Юктан барлыкка ирешү –
Дөньяда иң зур форсат...

Якты дөньяга тап булу –
Колач җитмәслек отыш.
Күктә атылган йолдызны
Артыннан куып тотыш...

Бар һәм бер булып яшәгәч
Ачы-төчесен татып...
Дөньядан китә алу да
Үзенә күрә бәхет...



Валентин ДУБИНИН



Валерий ТАРАСЕНКО

Гүзәл СӘНГАТУЛЛИНА

Пандемия зәхмәте

Бу пандемиядән соң бигрәк үзгәрде балалар. Дистанционкада телефон аша гына укып, шул телефоннан бер өзелмиләр хәзер. Ничә ел үтсә дә.

Җәйге каникулда да оның телефонынннан аерылмады. Бүлмәсенә кергән саен күрәм: һаман телефонда.

– Улым, – мин әйтәм, – бераз куеп тор инде шул тартмаңны, әйдә, бергәләшеп чәй эчик, ашап алыйк.

– Юк, дәү әни, – ди, – минем вакытым юк. Уйныйсым килә.

Җәйләр сизелмичә үтеп китте. Көз җитте. Беренче уку көнне мәктәпкә үзем озатырга булдым малайны. Мәктәп ишегалдында балалар күп. Тик никтер алар берсе дә мәктәп ишегенә карамыйча, телефоннарына кереп киткәннәр.

– Улым, бар, классташларың белән исәнләшеп ал, сагынгансыздыр бер-берегезне.

– Әй, дәү әни, син берни белмисең! Хәзер телефон аша гына аралашыла бит...

– Ә менә без укыганда мәктәпкә килү белән, шатланышып, укытучы апабыз янында җыелыша идек. Укытучыгыз кайда соң? Ник аның янына бармыйсыз? – дип соравымны дәвам итәм.

– Кем белгән, кайда икәнен? Хәзер безнең класс чатына язып җибәрер, белербез кайда булуын.

Минем соравымны белә торып, ул дәвам итте:

– Без дәрестә дә укытучыбыз белән чат аркылы гына аралашабыз. Бик җайлы. Кул күтәреп утырасы юк. Группа интернетта оештырылган. Шунда гына сорауларга җавап бирәбез.

– Ә билгеләрен ничек куялар?

– Хәзер көндәлекләр дә күтәреп йөрисе юк, рәхәт. Билгеләрне дә интернет аша гына куялар. Бер җитешмәгән җире генә бар – "ике"ле алсаң төзәтеп булмый, кәгазь көндәлектәге шикелле. Ә болай җайлы. Китаплар да күп ташымыйбыз хәзер. Барысы интернет аша гына бара.

– Өй эшләрен ничек эшисез?

– Әй, дәү әни, безнең вакытта өй эше белән баш ватып утырасы юк. Интернетта әзер өй эшләре сайты бар. Шуннан гына күчерәбез...

– Алай икән.... Болай булгач, сез укытучыларыгызны да танымыйсыздыр?

– Шулайрак инде анысы, дәрес барамы – бара. Шул җиткән.

– Тагын бер соравым бар, улым, әти-әни җыелышлары ишетелми. Үзең әйтмисеңме, әллә җыелышлар хәзерге вакытта беттеме?

– Бетмәде. Анда йөрисе юк. Барысы да дистанционно бара. Әни телефон аша гына җыелышта утыра. Мәктәпкә барып вакыт әрәм итми. Барысы да шулай гына. Акчасын җыярга булсалар, карточка аша җибәрәләр. Бик беләсең килсә, укытучылар үзләре үзара хәзер интернет аша гына аралашалар бит. Җыелышлары да шулай була.

Менә сиңа мә! Бөтенләй тормыш үзгәргән икән! Озакламый ата-ана балаларын таный алмас, балалар – ата-анасын. Пандемия бетте, чире калган икән. Әле ярый әбиләр бар, авылга кайткач аралашырга. Анда интернет начар эшли.

СҮЗ ИЯРӘ – СҮЗ

Башы аның шәп эшли иде, бигрәк тә тешләре.

Байлар үзләрен мөлаемлык һәм акыл өчен яраталар дип уйлыйлар.

Хәзерге заманда иң шәп кияү – кредитсыз кияү.

Фикер йөртүчеләр күп – акыллылар аз.

Цивилизация җимешләре белән дә агулану мөмкин.

Әгәр сәламәтлекне сатып алып булмый икән, нигә безгә түләүле медицина?

Чын ир кеше йорт салырга, агач утыртырга, ир бала үстерергә тиеш. Ә калганы – хатын нәрсә куша.

Бизнеслары күләгәдә булганнар көньяк кояшында ешрак җылына.

Ялгызлык – ул хәтта телефон мошенниги шалтыратуына да шатлану.

Виталий ВЕСНИН

Афродизиак

Бер тапкыр дустым туган көнемә ирләр өчен махсус духи – афродизиак бүләк итте. Ни өчен мондый бүләк икәнен болай аңлатты – үзенә генә өйләнеп яшәве авыр булмасын, миңа да өйләнеп интегү язсын дигәндәй, ярым шаяру белән әйтте ул бу сүзләрен. Бүләген алдым да аны тумбочкама куйдым һәм барлыгын да оныттым. Байтак вакытлар үткәч, киногa барыр алдыннан тумбочка актарганда шул флаконга күзем төште. Һәм кызык өчен генә моның тәэсирен сынап карау йөзеннән, янәмәсе кызлар "акылдан шаша" икән дигәннән, сибендем.

Билет алдым да холлга үттем, афишалар карап йөргән булам, кино башланганын көтеп. Карыйм, бер кырыйда кызлар утыра, янәшәләреннән генә үтеп китәм, үзем күз кырыем белән генә аларның реакцияләренә игътибар итәм. Байтак кына вакыт әрәм итеп, бернинди дә игътибар булмавына көенеп, төкердем дә бу эшкә һәм читтәге буш эскәмиягә барып урнаштым. Янәшәмә бер кыз килеп утырды, бераздан миңа дәшә:

– Сәлам!

– Сәлам! – дим аңа, афродизиак чүтеки эшли ахрысы дип уйлыйм бит инде.

Танышып киттек, сөйләшәбез. Кыз болай төскә-биткә чибәр, әле акыллы да икән. Сөйләшә торгач, вакыт тиз үткән, сеанс башланырга звонок бирделәр. Танышуымны ныгытырга теләп, аңа кинодан соң кафега керергә тәкъдим иттем. Ул минем тәкъдимемгә каршы:

– Гафу ит, булмый. Дөресен генә әйткәндә, миңа синең парфюмың ошады. Ничек дип атала, исеме ничек, мин аны үземнең йөргән егетемә бүләк итәр идем... – диде.



• • •

Юл эшчеләре нигә юлны елга ике тапкыр ремонтлауларын аңлаттылар – яз көне алар җәйге асфальт салалар, ә көз көне – кышкыны, ул йомшаграк була.

Александр АЛЁШИН



ТИШЕК КӨПЧӘК

ТИЗЛЕК ӨЧЕН ЙӨЗ ГРАММ

"Исерек килеш руль артына утыру – җинаять!" дигән тәгълимат искерде ахрысы. Дөресен әйткәндә, байтак шундый әһәмиятле әйтемнәр дә онытылып бара. Хәзер тамак чылатып алгач, кәперәеп машина йөртергә утыру геройлык булып санала. Нихәтле генә кисәтмә, нинди генә хикмәтле сюжетлар күрсәтмә, шул исерек шофёрларның кыланмышларыннан килеп чыккан фаҗигаләрне, аларга барып җитми, колакларына да элмиләр, барыбер стаканның төбенә чаклы чөмерәләр.

Бераулар, Түбән Камадагы август кичләренең берсендә, бик кәефләнеп утыралар. Әлбәттә, квас эчеп кенә түгел, икесе дә бер-берсен кысташа-кысташа шактый вакыт шәраб парларына күмелеп һәм коенып алганнан соң төнге шәһәр буйлап кәеф-сафа корып йөрергә уйлыйлар. Ләкин җәяү йөрү генә боларның ниятен канәгатьләндерми, шуңадыр бу ике дус тизлекне арттырырга ниятлиләр. Юл кырыенда торган машиналарның ишекләрен тарткалый башлыйлар. Берсенеке ачылып китә. Хәтта кабыза торган ачкычы да урынында– аңгыра хуҗа, мөгаен, онытып калдырган. Төнлә йөрергә яраткан әлеге исерекләр бу уңайдан файдаланып алырга уйлыйлар, кереп утыралар да газга басалар...

Төнге сәгать өчтә йоклап ятучы Бузов урамы кешеләрен чинатып басылган тормоз тавышы һәм берничә каты бәрелү гөрелтесе уяткандыр – тәрәзәләрендә утлар кабызу шуны искәртте. Куып алып киткән автомобиль зур тизлектә каршысына очраган чүп савытын да чөеп ыргытты, инде кайдадыр тукталырга теләгән чакта өч иномарканы урыныннан кузгатты һәм газонга очты. Мондый хәл бу ике дуска ошамады, күрәсең, алар качарга уйлады, әмма озакка түгел. Хәзер аларны китергән зыян өчен шактый күләмдәге түләү мәсьәләсе көтә.

"Яшь бит әле алар, тәҗрибәләре юк!" – дип уйлар иде шушы Шумахерлар турында кырык тугыз яшьлек Казандагы такси йөртүче Ш-ев. Йөртү тәҗрибәсенең күп булуы аны мондый бәлаләрдән коткара, дисезме? 8 август төнендә ул үзенең "бензобагына" йөз грамм салып куйган – тизлек өчен. Газ педаленә ныгытып басып, арендага алган "кытай"ын шеренгага тезелгән баганалар арасыннан, Сәлимҗанов урамы буйлап алга ыргылган. Бер баганасы нигәдер ошап җитмәгәнме, ул бөтен тизлеге белән шуңа китереп бәргән. Бамперы белән капотын күз алдына китереп тасвирлау мөмкин түгел.

Әле бу хәл ничек килеп чыкканын аңламаган автоковбой, юл инспекторларына руль артына ник утырганын аңлата алмый интекте. Күрәсең, баганага бәрелүе хәтерен чуалткан. Ә гаишникларның фикере башкачарак иде. Бу турыда алкотестер ап-ачык күрсәтте. Ләкин таксист-куучы килешергә һаман теләмичә маташа, янәмәсе ул үзен бик яхшы хис итә, хәтта шушы минутта космоска да очарга әзер! Ләкин "космонавт" булырга туры килмәгәнгә күрә аңа алдагы ике елда җәяү йөрергә кушылды.

Шушындыйрак хәлләр республикабыз юлларында еш булып тора. Кызганыч, әмма алар барысы да хәвефсез тәмамланмый. Кем дә булса бу хакыйкатьне аңларга теләми, алкогольле "заправкалар" андыйларга гомер юлының бер генә очлы икәнен төшендерәсе килә. Үкенечле булмасын...

Айдар СУБЕЕВ


Вячеслав ШИЛОВ


Сергей КОКАРЕВ



Николай ВОРОНЦОВ



Людмила САФИУЛЛИНА

ЧАМА БЕЛӘН

Бүгенге көндә тиешле медицина җиһазларыннан башка дөрес диагнозны һәр табиб куя алмый. Ә менә Мәүлетов урамы, 2 нче йортта урнашкан травматология пункты белгечләре сөяк сыну һәм имгәнү белән эләккән пациентларга ярдәмне чама белән, карап кына һәм үз тәҗрибәләренә таянып күрсәтәләр.

Инде берничә ай бу ноктада рентген аппараты эшләми һәм аны ремонтларга финанс мөмкинлеге юк. Сәламәтлек саклау идарәсендә яңа аппарат алу тулысынча министрлык карамагында, дип белдерделәр, ә тегеләре исә бу озакка сузыла торган нәрсә, дип аңлаттылар. Башта акча бүлеп бирәләр, аннан соң аукцион уздырып, җиңүче белән контракт төзиләр. Ә иске аппаратны рәтләү ноябрь башына, бозлавыклар вакытына планлаштырылган. Сәламәтлек саклау чиновниклары җаваплылыкны бер-берсенә аударып уйнаган арада, шәһәр кешеләренә саграк булырга, имгәнмәскә тырышырга кирәк.

Ләбиб ЛЕРОН

БЕР ЯШИСЕ ИДЕ ЧЫН-ЧЫНЛАП...

Уянасы килә, уйланасы –
Арынасы килә чылбырдан...
"Күптән инде, күптән яшәгән юк",
Бер яшисе иде чын-чынлап...

Алхимиклар ярдәм итә алмас –
Олгаермын, әмма яшәрмәм...
Умырыплар ашаган бар ансы,
Яшәгән юк, әмма, яшәгән!

Өсләр бөтен, тамак тук шикелле,
Акча да бар кебек өлешчә.
Тыйнак кына, җыйнак кына итеп,
Бер яшисе иде кешечә!

Ничәмә кат чирдән терелгән бар,
Юкса күпме генә яшәлгән...
Җирдә яшәү насыйп булмый икән,
Үлгәч кенә кала... яшәргә!



Игорь КИЙКО




Валентин ДУБИНИН

Ике табиб очраша. Берсенең кәефе бик кырылган
– Нәрсә булды? – дип сорый аннан коллегасы.
– Беләсеңме, кичә гомеремдә беренче тапкыр дәвалау хатасы җибәрдем.
– Ничек инде? – дип сорый иптәше.
– Миңа ике килудә терелттем бер авыруны, ә ул миллионер булып чыкты.



Валерий ТАРАСЕНКО



Алмаз ХӘМЗИН фотосы.

"ХОККЕЙЧЫ" ДЯДЯ САША

Безнең подъездда дядя Саша яши. Дядя дип әйтүем, бәлки, туры да килеп бетми торгандыр... Чөнки ул яшьрәк булырга тиеш – йөзгә карап, кеше хәлен чамалау авыр, мөгаен, аңа илледән артыграктыр – шулай дип уйлыйк. Хәер, анысы бик мөһим дә түгел. Шәп кеше ул – һәрвакыт ачык, очраган бар кешегә игелек теләп кала – күңеле саф, тик аның янында тукталып тормыйлар, елмаеп, "спасибо, спасибо!" дигән булып үтеп китәләр. Аның изге теләкләре кеше ераклашып, күренми башлаганчы озатып кала. Менә шул Дядя коронавирусны белми дә калды – без аның ничек дәваланганын белә идек, ләкин кулланып караганыбыз булмады, чөнки ул "дару" дозасын бик күп дозада куллана иде. Кая безгә андый куләмгә чыдау?.. Инде сәламәтлеге тагын да арту сәбәпле, "егетләрский" фасонда, җиң сызганып эшкә кереште. Күпсанлы кибетләр алдын чисталыкта тота: себерә, чүбен җыя, тәртип саклый һәм шулай ук элеккечә "сәлам"нәр җибәрә, әмма – "ни грамм!" Әнә, рәсемнә карагыз әле, саргайган яфракларны ничек җыю әмәлен тапкан! Себерке белән себереп җыюы кыенрак бит андый чүпләрне, ә хоккей клюшкасы шәп җайланма – корал! Мактадым үзен.

– Саша! – дим, – син молодец! "Башка"ң соображает! Ты, наверное, раньше хоккеистом был?

– А что? Я раньше в команде "Нефтяник"а нападающим считался! Менә бит ничек булган!

Мәйтәм:

– Син безнең "Ак Барс"ка барып карале! Анда что-то не ладно... Яфрак җыйганны, шайбаны гына йөгәнләрсең...

Көлә.

Алмаз ХӘМЗИН

Евгений ОБУХОВ

МӨГАЕН, ШУНДЫЙ КӨНГӘ КАЛЫРБЫЗ

– Күптәннән опера тыңлаганыбыз юк, – диде ире. – Җыен, Зур театрга барабыз.

– Зурына? – дип ачылып китте хатыны.

– Юл аркылы переходтагы Зурына. Анда бүген танылган җырчы үзе җырлый.

Переходта колак тондыргыч тавыш һәм бик күп кеше иде. Петров үзе тыйнак кына башын игәли, рояль капкачына охшаган переход кафель плиткаларына таянгандай итә. Вакыт-вакыт катыргы тартмадан акча купюралары тартып чыгара да икенче арияне җырларга тотына.

– Ә бүген кая барабыз? – дип сорады икенче көнне хатыны.

– Бүген филармониягә, скрипкачы-виртуозны тыңларга.

Филармониядә кием-салым сату ярминкәсе гөрли. Алар лотоклар аралап үтә торгач, скрипкачыны күрделәр. Ул бадрәфкә бара торган баскычта уйный иде.


Алдагы баруларында алар җыр һәм бию ансамблен карадылар. Моряклар бик тә шәп итеп, җырлый-җырлый "Яблочко"ны биеделәр. Кара мыеклы сатучылар яратып карап тордылар.

– Ярар, җитәр гел күңел ачып йөрергә, – диде ире икенче көнне. – Укуны да карарга кирәк. Бүген билгеле профессор химиядән зачёт кабул итә.

Профессорны алар бик тиз күреп алдылар. Ул переходта, җиргә гәҗит түшәп, үзенең фәнни китапларын сата иде.



Валерий ТАРАСЕНКО


Михаил ЛАРИЧЕВ

Абау!

БАШКАЛАР ӨСТЕННӘН

2 нче төзәтү колониясенең элеккеге башлыгын рәсми вәкаләтләрен арттыруда гаепләнә. Аерым алганда, ул бер тоткынның муенына нык утырган. Башта ул тоткынга инспекция комиссиясе әгъзаларының төшке ашына ризык алырга кушкан. Өч ел эчендә тоткын миллион сумга ризык китергән. Ләкин туймас начальник моның белән туктамаган. Аннары ул 8 Мартта учреждение хезмәткәрләре өчен 200 лалә чәчәге, офисы өчен телевизор һәм аудио система сатып алуны һәм үз хатынының машинасын ремонтлауны таләп иткән. Моның урынына, ул хөкем ителгән "иганәчегә" колониягә 50 тавык алып керергә һәм аны әзерләп хөкем ителүчеләргә сатарга рөхсәт биргән. Авыр мөнәсәбәтләр хәзер суд тарафыннан бәяләнәчәк.

ЯЛГАН БАЛАЛАР

Актанышта, дәүләт субсидияләре белән эш итүче эшкуар хатын кулга алынган. "Берлеген" шәхси балалар бакчасы хуҗасы Гөлнара Гараева, Мәгариф министрлыгына документлар тапшырганда, үзенә "ялган" балалар яздырган. Бу еллар эчендә ул уйлап чыгарылган укучылар өчен икедән өч миллион сумга кадәр акча алган. Гомумән алганда, Актаныш Мэри Поппинсы дәүләттән 10 миллион чыгарырга өлгергән.

ОЗЫН ЮЛ

Алабугада бер кеше тукталыштан ук автобус урлаган. Шоферы су сатып алырга киоскка киткән, ул вакытта салонда өч пассажир булган. Карак "хуҗасыз" машинаны күреп, руль артына утырган һәм ерак юлга кузгалган. Ярсыган пассажирларны беренче тукталышта төшереп калдырган һәм күрше авылга ашыккан. Соңрак, хокук саклау органнары хезмәткәрләренә аңлатуынча, аның кеше милегенә карата явыз нияте булмаган, өенә тизрәк кайтырга гына теләгән. Аны гаепләгән статья буенча, ул әле тагын өч ел өен күрмәячәк.

ТАБЫШ ОБЪЕКТЫ

Башкалар банк карталары белән алдаган вакытта, Кукмарада яшәүче юа торган чистарткычны мошенниклык объекты итеп сайлаган. Ул сайт аша 35 мең сумлык техник җайланманы арендага алган. Ләкин аны максаты буенча кулланырга уйламаган. Кешеләрдә гомуми чистарту уздырыр урынга, җиһазны ломбардка тапшырган, моның өчен акча алган һәм аны үз мәнфәгатенә сарыф иткән. Чистарткыч мошенник өчен җиде ай төрмә һәм 20 мең сум штраф белән тәмамланган.



Михаил ЛАРИЧЕВ



Максим СМАГИН



Валентин ДУБИНИН

Рәдиф СӘГЪДИ

БУТАЛЫШ

Беднең, гафу итегез, безнең халыкның бүлгәләнергә яратуы барыбызга да мәгълүм. Кемдер үден, гафу итегез, үзен я Болгар, я Балкар, я Башкорт, я Ногай, я Гагауз, я Мишәр, я Типтәр, я Керәшен, я Уйгур дип атарга ярата. Нәмә һоң был?! Был төркиләрнең күп бичәләр алып үрчүләреннән килә, дип уйлыйм. Әле монда бер анадан туып та тынгылык күргән юк! Мал бүләбез, чүп өябез!

Башкортстаннан дустым Рамил Чурагыл белән энесе Камил килә дә, миндә чәйләп-мәйләп китәләр. Малай, чәйне дә беднеңчә, ягъни сезнеңчә, то есть минемчә эчәләр, тәгәри генә шешәләр. Ләкин аларның килүе минем егәремне күтәрә. Чөнки алар мине Башкортка да, Татарга да, Уйгырга да ошатып яраталар. "Урыска гына охшамагансың икән, Рәдиф Сәгъди", – диләр,ә мин аларга җавап итеп:

– Урыс миңа охшагандыр, – дип куям.

Алар, күз салып тикшереп чыккач:

– Точно! Новгород урыслары койган да каплаган син инде. Шулай да Сибай башкортлары чалымы көчлерәк синдә!

Ә кем белә, бәлкем, шулайдыр да, энидән сорасыннар. Әмма миндә керәшен чалымнары да җитәрлек. То есть керәшеннәрдә – минем чалымнар. Гәрәй Рәхимгә генә карагыз: койган да каплаган минем малай инде. Гәрәй Рәхимегезнең кыяфәте. Фамилиясе генә дә кемлеген әйтеп тора бит! Рәхим, Рәхим Гәрәй! То есть һәркемгә дә рәхимле, особенно хатын-кызларга рәхим-шәфкатьле дигән билге бит бу! Ну, малай, мәчеткә генә йөрми, чукынчык.

Шулай үземнең малай турында уйлап утырам әле. Ахыры бында, то есть монда, Башкорт та, Татар да, Балкар каны да бардыр дип. Ну малай, матур инде минем малай үзем кебек. Бәлки ул Керәшен дә, Башкорт та, Ногай да түгелдер әле! Ә бәлкем Гагауз, Уйгырдыр.

Үземнең башка да кайчагында тиле-миле уйлар керә. Әллә мәйтәм Уфа якларына китеп башкортлар белән туганлык җепләрен тагын да ныгытып кайтырга инде. Юк, булмай икән! Чөнки Татарстан белән Башкортстан авыллары хатын-кызлар чырае күрмәгән ирләр белән шыгрым тулы. Аллам сакласын, кеше өлешенә керергә! Соңыннан мине яманлап:"Туксан хатынга өйләнде, аның аркасында без коры калдык", дип каргамасыннар мине. Үзләре белсеннәр үзләренең буш куык икәнлекләрен. Алар өчен дә мин өйләнеп йөри алмыйм ич инде! Аннан соң кайсы оланым Башкорт, кайсы Гагауз, кайсы Балкар, кайсы Татар икәнлеген ачыклап бетереп булмаячак. Юк, мин бу эшкә бара алмыйм. Теге өйләнә алмый йөргән "оланнар" өлешенә дә керә алмыйм. Бәлкем алар да әле бер селкенеп куярлар. Селкенеп, Башкорт, Татар, Ногай халкын арттыруга изге өлешләрен кертерләр.

Хәбил ТУКМАНОВ

ЧАМАСЫН БЕЛИК...

Туктатып булмый вакытны,
һәрбер нәрсә – вакытлы,
Бирелмик төшенкелеккә
һәм кыскартмыйк шатлыкны...

Күп нәрсәнең үзебездән
Торганын да беләбез,
Ә белсәк тә, кайвакытта
Баткаклыкка керәбез...

Иминлек саклау теләге
Яши бит күбебездә,
Ә шуны тормышка ашыру
Була соң күпмебездән?

Төрле хәтәр чорлар булган,
Хәзер – гаджет заманы.
Нинди чорда яшәсәң дә
Белү кирәк чаманы.

Чамасын белмәүчеләрнең,
Кызганыч, саны арта;
Җир шарының исән чагы
Калмасын иде артта...

Чама белсәк, акрынлап,
Бәлки, алга барырбыз.
Ялгыш таеп егылмасак,
Кеше булып калырбыз...



Александр ШУЛЬПИНОВ

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

ҮРДӘК АВЫЗЛАРДАН КУРКАМ

Безнең авылда Чамалы Хәлиле бар иде. Һәрнәрсәнең җаен белеп, артыгын кыланмый яшәде ул, кушаматы үз-үзен тотышына тач иде. Кайвакыт минем Чамалы Хәлилен терелтеп, бүгенге көнгә кайтарасы килә. Минем белән бер-ике сәгать телевизор карап утырса, иманым камил, үзе яраткан «нихрина сибә»сен әйтеп, урындыгыннан егылып төшәр иде ул.

Соңгы вакытларда үзем дә телевизор кабызырга курка башладым. Курку түгел инде ул, гарык булу, күңел кайтумы шунда... Мине экранда «үрдәк ирен»нәрнең һаман арта баруы гаҗәпләндерә. Гаҗәпләндерә генә түгел, куркыта да. Ирен кабарту мода кысасыннан чыгып, йогышлы авыруга әйләнмәде микән, дип куркам. Гүзәл затларыбызда чама хисе, зәвык дигәннәре бетте микәнни? Бу язманы укыганнар арасында: «Риман меж-меж картка әйләнгән икән», – диючеләр дә табылыр. Әмма мин аларга үпкәләмим, бәлки, мин теге гасырда ук калганмын, заманны һәм аның кешеләрен аңлап бетермимдер, дип уйлыйм.

Шулай уйлый-уйлый, «ВТ» кызларыннан ирен кабарту мәсьәләсе турында сораштыра башладым. Сәрия Мифтахова: «Чамасын белсәләр, бераз ярыйдыр ул», – дип көзгедән үз иреннәрен карап куйды. Үзенә бик килешле, матур аның иреннәре. Аннан Эльвира Вәлиевага «бәйләндем». «Иреннәреңне ник бераз кабартмыйсың?» – дидем. Башта миңа сәерсенеп карап торды бу. Аннан соң бер гыйбрәт әйтеп куйды. Аның биш яшьлек улы Самир: «Әни, чәчеңне, керфекләреңне буятасың килсә буят, ну үрдәк авыз ясатма, яме!» – дигән. Укучыларыбыз, бәлки, көлеп куяр, «Самирга зурлар акылы кереп җитмәгән, ә Риманныкы чыга бара», – дип уйлаучылар да булыр.

Инде төрле яшьтәге күпме кешедән, ирләрдән һәм хатын-кызлардан да сораштым һәм Самир белән Риман кебекләрнең күпкә артык булуына шатландым. Шул ук вакытта чама хисен югалтканнар саны артуына борчылдым.


Беркөнне телевизордан төрле тапшырулар алып баручылар һәм аларда катнашкан гүзәл затларыбыз арасында «үрдәк авыз»лар күпме икәнен санап утырдым. Якынча алганда, 70% чамасы чыкты алар.

Заман модалары йөз, күз, иреннәрдән – күкрәкләргә, күкрәкләрдән арт шәрифләргә төшә башлады. Инде гүзәл затларыбыз аякларын гына зурайтмасыннар. Без – ирләр 42–45 нче размерлы туфли кигән хатын-кызны күрсәк, нинди хисләр кичерер-без икән? Монысын шаяртып кына әйтәм инде. Ә менә сыйпаганда безгә дәртле, матур хисләр бирә торган хатын-кыз тәне татуировкалар белән капланып бетсә, нишләрбез, гүзәл затларыбызның кай җирләрен сыйпарбыз, кай җирләрен «пәп» итәрбез икән?

Боларны язганда, үзем дә чама хисен югалткан булсам, гафу итәрсез инде. Табигый матурлыкны югалтасы килмәгәнгә генә әйтәсен әйтеп карыйм, дидем. Ә авылдашым Чамалы Хәлиме, мөгаен: «Карале, халык маймылга әйләнгән бит», – дияр иде дә, әлбәттә инде, «нихрина сибә» дип тә өстәр иде.



Герман ОГОРОДНИКОВ, 1969 ел.



– Әти, сине тагын чакыралар!
– Мәктәпкәме?
– Кечкенә түгел бит инде мин. Милициягә!

Леонид ЕЛЬКОВИЧ 1975 г.



• • •

Олигарх өенә кайта. Хатыны:
– Кич инде, ашыйсың киләме?
– Ә нәрсәң бар?
– Омар, икра, бургунд шәрабы...
– Их, ярып кына пешерелгән кабыклы бәрәңге ашыйсым килә!
– Ә син башка мужиклар кебек эшлә, бәрәңге дә булыр!

• • •

Исәнмесез, сез ашыгыч ярдәмгә шалтыратасыз! Сезнең шалтыратуыгыз безнең өчен бик мөһим. Әгәр сездә инфарк икән, бер санына басыгыз. Әгәр инсульт булса – икегә. Әгәр йөрәк өянәге – өчкә. Алай көтеп алалмасагыз ритуаль хезмәт операторына шалтыратыгыз.

• • •

Бер ир яр буйлап кычкырып чаба:
– Вәт әшәке балык!
Балыкчылар сорый моннан:
– Нәрсәгә акырасың?
– Алтын балык тоткан идем, аннан яңа йорт сорадым, үзен җибәрдем, ә өйгә кайтсам, 30 елга ипотека договорын күреп шаккаттым.

• • •

Кадрлар бүлегендә:
– Сезнең ике югары белем дипломы икән?
– Әйе, җир асты переходында акция бара иде: ике диплом – бер диплом бәясеннән.

• • •

– Беләсеңме, сине банкрот дип чутласыннар өчен, судка мөрәҗәгать иткән өчен 10 мең түләргә кирәк?
– Әгәр минем 10 меңем булмаса?
– Димәк, син хәлле кеше.

• • •

Төгәл диетада утырам: иртән – йогурт, төшкә – лимонлы чәй, кичкә – җиңелчә итле салат, колбаса, каймак, пилмән, тавык ите, күмәч һәм балык...

• • •

Иртән-иртүк бер ир өеннән чыккан, ни күрә – күршесендә өр-яңа машина тора.
– Кара инде моны! Эшемдә шелтә алдым, улым начар укый, хатыным сүгеп тора... Үземнең җитешсезлекләрем муеннан, җитмәсә, күрше машина сатып алган!

• • •

– Әбекәй, Интернетсыз ничек яшәдегез?
– Әйбәт, улым, әйбәт.
– Әгәр безнең Интернетны сүндерсәләр, без дә әйбәт яшәрбезме?

Күзге елмаюлар



Виталий ПОДВИЦКИЙ



Сергей КОКАРЕВ



Анастасия ВАСИЛЬЕВА





НУ ЭШЛӘП ТӘ КҮРСӘТКӘННӘР!..

Советлар вакытындагы "Бөтен яхшылык – балаларга!" дигән лозунг хәзерге заман чынлыгында шактый үзгәрде. Бүген балаларга дигән яхшылык – кайберәүләргә генә. Безнең Ибраһимов проспектындагы 59 нчы йорт ишегалды мәйданында электән калган тимер лабиринт бар иде, күрәсең ул шәһәребездә уңайлы яшәү шартлары концепциясенә туры килмәде. Төзелеш эшләре башланды, яңача уен зоналары төзергә дигән вәгъдәләр бирелде. Лабиринтны сүттеләр, ә аның урынына икенче йорт ишегалдыннан инде срогы чыккан корылмалар алып килделәр. Безнең балалар "Үзең төзе" дигән конструктордагы сыман мәйданчыклы булдылар. Черек борыслы агач йортлар, җайлы-җайсыз таучыклар, сәер кыяфәтле тарзанка, әллә нинди кирәкле-кирәксез пыялалар. Бонус сыйфатында – теләсә кайдан калкып торган кадаклар, арматуралар барысы да теге иске лабиринттан.

Хәтта балалар да, үзләренең чиксез фантазияләре белән, бу галәмәтләрнең ни өчен икәнен аңлый алмый аптырап тора. Ә без, ата-аналар, инде бу урынга балаларыбызны уйнарга чыгарырга куркабыз – монда бит, Аллам сакласын, аларның бәла-казага юлыгулары бар.

Ибраһимов урамындагы 59 нчы йорт халкы.

КАЗАН

НИШЛӘРГӘ БЕЛМӘГӘЧ, ЗАРЛАНУ

"Хәрәкәттә – бәрәкәт!" диләр халыкта һәм медицина да шул фикердә. Шуңа өстәп саф һаваны кертергә мөмкин, тагын җан тынычлыгын. Мәсәлән, бездә, Казан артындагы "Совушки–Ябалаклар" бистәсендә (ул Биектау районына керә), бу сәламәт яшәүгә кирәкле нәрсәләр барысы да бар. Бигрәк тә җәмәгать транспортының булмавы сөендерә. Гәрчә монда торучыларның фикере киресенчә кузаллана – 93 нче автобусның маршрутын бистәгә хәтле озынайту таләбен кузгату. Кыен түгел бит инде әлеге юл юнәлешен ике километрга сузу. Ләкин транспорт министрлыгында һәм җирле администрациядә бу үтенеч тамырдан киселә: янәмәсе, файдасы юк. Без мондый караш белән килешеп бетмибез, барлык гаиләләрнең дә шәхси машиналары юк (инде бистәбездә 400 гә якын кеше яши). Түрәләрнең әлеге фикере күпләр тарафыннан яклау да таба, әлбәттә. Сәламәт кешегә автобусның якынрак тукталышына атлау утыз гына минут та бит... Җәяү йөрү, мәгълүм, йөрәк тибешен җайга салу өчен менә дигән алым. Ләкин авыру кешегә өйдә генә утырырга язганмы, саф һавадан мәхрүм калу – санап бетергесез кыенлыклар, ягъни хастаханәгә барып җитү барысының да көченнән килми.


Биектау районының "Совушки" бистәсендә яшәүчеләр.






Сергей КОКАРЕВ







Зөфәр АХМӘТҖАНОВ

ДРОННАР ГЫНА КИЛМӘСЕН!

Кайвакытны "еларгамы-көләргәме?" дигән сорау туа. Менә шунда, РКБ больницасында, кем операциядән, кем чират көтеп палатада ятканда бер вакыйга булды. Кичке уннар узып барганда, кинәт дөбер-шатыр атыш тавышлары яңгырады. Дөньяларның тынгысыз чагы бит. "Дронга" аталар дигән уй баштан йөгереп үтте. Корпуслар арасы өч яктан каплаулы булганлыктан, шартлаулар көчле яңгырады. Күпләр, сискәнеп, тәрәзәгә үрелде. Күктән төрле төстәге утлар коела башлагач кына, бу – салют икәнен шәйләдек. Бер бәхетле ата шатлыгын уртаклаша ахрысы дигән фикеремә шаян Рәис каршы төште. Берәрсенең тёщасы үлгәндер әле, дип, киеренкелекне басарга тырышты бугай. Үз хәле хәл булган Рифат кына: "Вакытлы-вакытсыз тумасыннар да, үлмәсеннәр дә!" – дигәч, һәркем үз уена чумды.

Алда әле сырхаулы озын төн, уйланырга вакыт җитәрлек. Тик шул "дрон" дигәне баштан китми. Иртәгесен хәбәрләр программасы бу хәл турында сүз куертты. Әммә тормыш үз агымы белән ага иде инде.

Алмаз ХӘМЗИН

КЕМ СОҢ БЕЗ?

Мы не рабы – рабы немы!

Хәзер рәхәт, бик тә рәхәт –
Берни эшләргә ярамый...
Ярамый күпне күрергә:
Ишетергә, сөйләшергә,
Белергә, өйрәтергә һәм
Төрттерергә, чеметергә,
Көләргә дә, еларга да,
Хәтта юньләп уйларга да,
Шыңшырга да, мырларга да,
Язарга да, сызарга да...
Уларга дә...

Инде хәзер беттек диеп
Әйтсәк ярый, әйтә алсак:
Саңгырау без, сукырайдык,
Аңгыраландык, сүзсез калдык,
Телсез калдык, чукракландык,
Маскаландык, мыскылландык,
Җәберләндек, күндәмләндек
Һәм мүкләндек...

Инде менә без кем соң,
Бармы терәлер җаебыз?
Илсез калырбыз, җирсез дә,
Хокуксыз да, ирексез дә,
Намуссыз да, вөҗдансыз да,
Имансыз да, әхлаксыз да,
Әле телсез, Ватансыз да...
Соңыннан сорарлар бездән:
"Кем соң сез?.."

ТӨЗӘТМӘ

Кызганыч, "Чаян"да да хаталар киткәли. Мәсәлән, 9 нчы сандагы Евгений Бугров язган "Хоттабыч карт" хикәясе башка исем астында басылган. Дустыбыз һәм даими авторыбыздан гафу үтенәбез. Әйтергә кирәк, Евгений Викторович үзе бу хәлне юмор белән кабул итте: тылсымчы картллач менә битниләр кылана, дип...

Рәшит МИНҺАҖ

ОХШАШЛЫК ДӘВАМ ИТӘ

Уены-чыны бергә кайный –
Кашың нинди, башың шундый.

Каш дигәч тә, син үзең кем булдың соң: кашың нинди дә үзең нинди, диярсез. Җәмәгать, кашым нәкъ үзем кебек. Урыны-урыны белән сыек, куе төшләре дә бар. Мин – кем! дип тырпаеп торган керфекләре дә аз түгел. Ие, күңелкәйләр кашым сыман чуар. Яшь чагымда, кызларны өч көн озата да, күңеле суына, яңасына күзе төшә, дип үртиләр иде. Шулай булды шул. Хәзер кызларның күбесе, абый, ди. Абзый, дип әйтүчеләре дә очрый, рәхмәт төшкереләре! Кашыма охшаганмын: кирәк-кирәкмәс урында чәчрәп чыга торган гадәтем бар. Шулай берьюлы матбугат җыелышында бер мәмләкәтнең Илбашына, латиницага кайчан күчәсез, башкалар күчеп бетә ич инде, дип сорау биргән идем, тегеләрнең солтаны кызып китте. Солтаннарның солтаны, печән чабасы бар, чуен эретәсе, юк-бар белән башны катырма, дип җавап кайтаргач, мине Патша сараена бүтән чакырмадылар. Тозсыз сораулар биреп, олы абзыйларны гасабиландырсаң, шулай килеп чыга икән.

Кешенең холкын ничек чамалап, белеп була? Холыкны билгеләүче иң төп күрсәткеч шул каш бугай...

Менә ике кешене генә алыйк. Коммунистлар партиясенең иң күренекле, ягъни иң мәһабәт, иң дастоен, гүәрдиндәй янарал секретаре Леонид Ильич Брежнев белән Камал театрының атаклы артисты, тозлы һәм борычлы мәзәкләр остасы Рәшит Шамкай.

Икесен дә халык үлеп яратты. Икесе дә кешеләрне үтә нык көлдерә иде. Менә Леонид Ильичның иң танылган, барча партноменклатура байрак итеп күтәргән шигаре – "Экономика экономияле булырга тиеш!" Шушы дүрт сүзгә барча бишьеллыкларның үтәлгән һәм үтәлмәгән планнары сыйган.

Брежнев белән Шамкайны нәрсә берләштерә, дисезме? Дөрес, каш! Гамәленнә ул характерлый!.. Берсе дәүләт масштабында көлке куертты, икенчесе шул куерткан оеткыдан мәгънә табып, халыкны котыртты. Рәхәтләнде халык көлеп шул җәһәттән... һәм менә хәзер көлке хәлендә калдык та инде. Алга таба шундый куе кашлар табылмас дип кем әйтер? Хәер, үзем төслеләре дә шулайрак кылана!..

Хәмид ВӘЛИДИ

ӘКРЕН ГЕНӘ, ИПЛӘП КЕНӘ...

Куды кичәге Сукбайны
Бүгенге Бомж илдән.
Әкрен генә, ипләп кенә
Куалар туган телдән.
"Йомшак" кергән күк базарга,
Ят сүзләр керә... йомшак.
Чит сүзләр: төсле, бизәкле,
Туган тел – ятим, "кыпшак".
Хакимият үз итмәгәч,
Һәр тел дә җуя көчен.
Үги илдә, Сукбай хәлдә
Чүплектә ауный, мескен...
ВУЗлары вә мәгарифе,
Радиосы юк аның.
Кандаладай Кортмән җаннар,
Суыра телнең канын.
Бар телне саклаучы Канун!
Өнәми тик түрәләр.
Ятсынып, "Әңгәмә" сүзен
"Интервью" дип бирәләр.
Дугадай бөгелеп татар,
Ялый ятлар табанын.
Аягүрә йоклап, сизми:
Телсез, илсез калганын.

Никифор ТУКМАЧЁВ

ЮЛЛАР

Артка борылып булса да
Алга барган көнебез.
Коммунага булмаса да,
Юллар салган көнебез.
Мәскәү–Казан юлларында
Чаба алырбыз микән?
Чапканнарны куллар болгап
Озатып калырбыз микән?
Ул юллар Кытайга кадәр
Барып җитәчәк, имеш,
Түбән Каманы әйләнеп,
Узып китәчәк, имеш.
Кытайны барып күрергә
Бер җай табылыр әле.
Яшьлеккә кайтара торган
Юл да салыныр әле.
Бәхет безгә үзе килә –
Инде бәхет юлдашым.
Коммунизм дигәннәре,
Бәлки, әле шундадыр.

Гаҗәп түгел, оҗмахка да
Юл салына башласа.
Бу дөньяда юньле тормыш
Күреп булмас башкача.



Ринат АБЗАЛОВ



ЧАЯН
САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ
1923 елдан чыга.
№ 10 (1947) октябрь 2024

Баш редактор:
Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ, Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
420047, Татарстан Республикасы, Казан, Академическая урамы, 2
Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.
Журнал Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты: ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.
«Журналга «Почта России» каталогы, йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша язылa алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).
Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» типографиясендә басылды.
420066, Татарстан Республикасы, Казан, Декабристлар ур., 2.
Чыгу көне: 01.10.2024 ел.
Тираж – 1916 Заказ А-2202
Редакциянең адресы: 420066, Татарстан Республикасы, Казан, Декабристлар ур., 2.
Белешмәләр өчен телефоннар: (843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru
16+
Бәясе ирекле

Уйна да, уйла да!



"БЕРСЕ ... БЕРСЕ ХӨРМӘ"

ЖЫРЧЫ ГӨЛДАНИЯ ...

ГӨУДӘЛЕ, ТАЗА

КАЗАНДАГЫ НӘШРИЯТ ҮЗӘГЕ

МАКТАУГА ...

БАСУЛАРДА ...

НОТА

"... МИЛЛИОН"

М. ЖӘЛИЛ ШИГЫРЕ

КАМА КУШЫЛДЫГЫ

КҮРӘЗӘ-ЛЕК

"СУТЫЙ"

"ЗӘҢГӘР ...(-1)"

"ҺӘМ" ИСКЕЧӘ

...-ТӨЯК

НӘНИ СССР-РОССИЯ АВТОМОБИЛЕ

УЕНДА ТУПНЫ БАШКА УЕНЧЫГА БИРҮ

ФИНАНС ОЕШМАСЫ

"СУ БУЕНДА ... ЯНА"

САТУРН-НЫҢ ИЯРЧЕНЕ

ЕВРАЗИЯНЕҢ ӨЛЕШЕ

ИҢ СИРӘК ХИМИК ЭЛЕМЕНТ

(-1)...-ШУ

СУНАРЧЫ

АХЫР

ЯҢГЫН ...СЫ

«ТУКТА, ...»

«... ЕРАК»

ХАЛЫК ЭЧЕМЛЕГЕ

ПРЕЗИДЕНТ ФӘРМАНЫ

"ЖИДЕГӘН ЧИШМӘЛӘРДӘ ЖИДЕ ..."

"БИК САГЫНДЫМ ... БУЙЛАРЫН"

САМОЛЁТ

...-ЖӘЯ

"...КАЕН"

"ДӨРТЛЕ, МАТУР ..."

ИР КАНАТЫ

БОРЧЫЛУ, КЫЗГАНУ

ЖАН-...

"... БӨГЕЛЕП ТОРА"

...(-1)-АНА

...КҮКРӘҮ

...ЧҮКЕЧ

"... УРМАН"

...КАЗЛАР

"БИБИСАРА ЙОКЛЫЙ АЛМЫЙ ..."



1. Хәзерге заман балалары нигә һәрвакыт компьютер каршында утыралар, ә элек ишегалдында футбол уйныйлар иде?
2. Күз килүенең иң төгәл билгесе нинди?
3. Иң файдалы туклану нидән гыйбарәт?
4. Кайсы язучыларны классиклар дибез?
5. Нәрсә ул антиквариат?
6. Нинди очракта безнең тормыш әйбәт һәм шаккатырлык булырга мөмкин?
7. Барлык уйлап табуларның Анасы?

ЖАВАПЛАР

1. Чөнки барлык ишегаллары машиналар белән тулган. 2. Салкын су кранынан салкын су килә башлагач. 3. Тиз әзер була торган токмачны кран суын сөзеп алганнан соң гына пешерү. 4. Мәктәп программасына кергәннәре. 5. Еллар буе аунап яткан иске-москы. 6. Барысына да игътибар биреп, сокланып яшәгәндә. 7. Ялкаулык.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда жыр исемен укыгыз.
Журналыбызның 9 нчы санында басылган чаянвордның тикшерү сүзе –
«СИНЕ УЙЛАП ЯНАМ».


Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:


Г. БАҺАВЕТДИНОВ (Чаллы),
С. ШӘЙХУЛЛА-ӘНӘЛЕ (Казан),
З. ЯРУЛЛИНА (Апас).

Җиңүчебез – Чаллыдан


Гали БАҺАВЕТДИНОВ!


Виктор БОГОРАД





Петербург – мәдәният мәркәзе генә түгел, карикатура башкаласы да. Бу кала күпсанлы карикатура графикасы осталары белән дә дан тота. Виктор Богорад – бу жанрның күренекле вәкилләренең берсе. Радиоинженер һөнәре аңа Петербургтагы «Нюанс» карикатурачылар төркеме рәссамы булып китәргә һич тә комачауламаган. Виктор Борисович – Художество академиясенең мактаулы әгъзасы, күптөрле призлар һәм бүләкләр иясе. Ә иң мөһиме – ул «Чаян»ның даими авторы. Бу вернисаж рәссамның 75 еллык юбилеена багышлана.







4 612750 670080